**ГЛАВА**
**Терсинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Тирсә авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2023 Тирсә авылы № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Тирсә авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге Башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын беренче этабын 2023 елның 22 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын икенче этабын 2023 елның 22 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын өченче этабын 2023 елның 22 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын дүртенче этабын 2023 елның 22 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.
5. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Тирсә авылы Көнчыгыш ур., Восточный тыкрыгы, Яшьләр ур., Первомайская ур., Мәктәп ур., Заречная ур., Яр буе ур., Нагорная ур. халкы.

-2 этап: Тирсә авылы Үзәк урамы халкы.

-3 этап: Тирсә авылы Полевая ур., Дружба ур., Мир ур., Луговая ур., Озерная ур., Садовая ур., Советская ур., Трудовая ур. халкы.

-4 этап: Тирсә авылы Вокзал урамы халкы.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны вак таш белән салу, урам юлларына хезмәт күрсәтү, грейдир белән йөрү, карны чистарту);
2. МТЗ-82 тракторын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, трактор өчен өстәмә җайланмалар сатып алу, кардан чистарту, үлән чаптыру, чүп-чар чыгару өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
3. Үлән чаптыру өчен бензин чапкычлар сатып алу, куакларны кису өчен бензин кискеч сатып алу;
4. Урамнарны яктырту өчен электр товарлары сатып алу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ».

7. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Тирсә авылы, Үзәк урамы, 163 йорт, авыл мәдәният йорты.

8. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

9. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

10. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

11. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык И.Б. Гиззатуллин